МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.11.2023 Казан ш № 858

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне (алга таба – Үзгәрешләр) расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә, әлеге боерык белән расланган Үзгәрешләрнең 2 пунктындагы дүртенче-җиденче абзацларыннан тыш, алар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, дип билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 2 ноябрендәге 858 номерлы боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларның берсе булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 5 ноябрендәге 920 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.02.2020 №70, 01.06.2020 №380, 09.10.2020 №718, 04.05.2021 №290, 17.11.2021 №846, 04.04.2022 №254, 08.07.2022 №671, 20.01.2023 №21 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган 18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларның берсе булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.6.1 пунктның 2 пунктчасының беренче абзацында «алты календарь ай» сүзләрен «ай» сүзе белән алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Түләүсез юридик ярдәм алу, курорт җыемын түләүдән азат итү, бала кирәк-яракларының бүләк комплектын алу, ташламалы шартларда челтәр оешмасы белән электр челтәрләренә энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме яки ялгыз яшәүче гражданинның кереме күләме турында белешмә бирү турында дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 11 июлендәге 397 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 08.06.2017 №349, 07.05.2018 №348, 18.09.2018 №885, 02.07.2019 №509, 15.11.2019 №1032, 03.02.2020 №52, 25.06.2020 №461, 05.10.2020 №698, 29.04.2021 №275, 22.06.2021 №438, 13.09.2021 №656, 14.04.2022 №276, 13.03.2023 №159 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Түләүсез юридик ярдәм алу, курорт җыемын түләүдән азат итү, бала кирәк-яракларының бүләк комплектын алу, ташламалы шартларда челтәр оешмасы белән электр челтәрләренә энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында шартнамә төзү өчен гаиләнең җан башына уртача кереме яки ялгыз яшәүче

гражданинның кереме күләме турында белешмә бирү турында дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.6.1 пунктының 2 пунктчасында:

икенче абзацында «алты календарь ай» сүзләрен «ай» сүзе белән алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«түләүсез юридик ярдәм алу хокукын билгеләү өчен белешмә бирү, курорт җыенын түләүдән азат итү, челтәр оешмасы белән энергия кабул итү җайланмаларын электр челтәрләренә ташламалы шартларда технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында килешү төзү буенча – гаиләнең һәр әгъзасы алган, гариза бирү ае алдыннан бер календарь айга кадәрге соңгы өч календарь ай өчен, аларга түбәндәгеләр керә:»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Чит ил дәүләтенең компетентлы органы тарафыннан бирелгән, мөрәҗәгать итүче яки аның гаилә әгъзаларының Россия Федерациясеннән читтә алган керемнәре күләмен раслаучы документлар (мәгълүматлар) мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рус теленә тиешле дәрәҗәдә расланган тәрҗемә белән тапшырыла.».

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 9 мартындагы 144 номерлы боерыгы белән расланган Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«баланың (балаларның) тулысынча дәүләт тәэминатында булуы;

мөрәҗәгать итүчене балага (балаларга) карата ата-ана хокукыннан мәхрүм итү (чикләү);

баланың опекада (попечениедә) булуы һәм опекун (попечитель) тарафыннан аны караган өчен акча алу;

гариза бирелгән балага карата ата-анада алимент йөкләмәләре барлыкка килү;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бирү.».